РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422055, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Старый Мичан, ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422055, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы,
12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.10.2024 № 19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 нче ноябрендә 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 ел, №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел № 24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.4.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 4.9.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы: А.Ә. Гәрәев